«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлегенең Колчык бистәсендә халык җыены нәтиҗәләре һәм 2022 елда үзара салым кертү турында» 2021 елның 24 ноябрендәге 2 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлегенең Колчык бистәсендә гражданнар җыенының карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә

«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Биеш авыл җирлегенең Колчык бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляскада йөрүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, күп балалы гаиләләрдән тыш) 500 (биш йөз) сум күләмендә 2022 елда үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча

- Биеш авыл җирлегенең Колчык бистәсендәге территорияләрне төзекләндерү (биек агачларны кисү);
- Биеш авыл җирлегенең Колчык бистәсенең су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау;
- Биеш авыл җирлегенең Колчык бистәсендә вак таш җәеп, юлларны ремонтлау һәм җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту

  эшләрен башкарырга юнәлдерү белән килешәсезме?» дигән мәсьәлә буенча 2021 елның 24 ноябрендә Колчык бистәсе гражданнары җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 23 кеше кертелгән, тавыш бирүдә кеше катнашкан гражданнар саны 14 кеше .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда 14 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлегенең Колчык бистәсендә халык җыенын узган дип, халык җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Биеш авыл җирлегенең Колчык бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляскада йөрүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, күп балалы гаиләләрдән тыш) 500 (биш йөз) сум күләмендә 2022 елда үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча

- Биеш авыл җирлегенең Колчык бистәсендәге территорияләрне төзекләндерү (биек агачларны кисү);
- Биеш авыл җирлегенең Колчык бистәсенең су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау;
- Биеш авыл җирлегенең Колчык бистәсендә вак таш җәеп, юлларны ремонтлау һәм җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту

эшләрен башкарырга юнәлдерү белән килешәсезме?» дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Биеш авыл җирлегенең Колчык бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган

яшәүчедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляскада йөрүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, күп балалы гаиләләрдән тыш) 500 (биш йөз) сум күләмендә 2022 елда үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча

- Биеш авыл җирлегенең Колчык бистәсендәге территорияләрне төзекләндерү (биек агачларны кисү);
- Биеш авыл җирлегенең Колчык бистәсенең су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау;
- Биеш авыл җирлегенең Колчык бистәсендә вак таш җәеп, юлларны ремонтлау һәм җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту

эшләрен башкарырга юнәлдерергә.

4.Әлеге карарны мәгълүмат стендындлары аша халыкка белдерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Биеш авыл җирлеге Башлыгы Р. А. Вәлиев